БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 01 2022 ел № 33

**Югары белем бирү мәгариф оешмаларында максатчан юнәлеш буенча укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясен төзү турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләре, «Урта һөнәри һәм югары белем бирү мәгариф программалары буенча максатчан укыту турында» 2020 елның 13 октябрендәге 1681 номерлы РФ Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Югары белем бирү мәгариф оешмаларында максатчан юнәлеш буенча укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясен төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).
2. Югары белем бирү мәгариф оешмаларында максатчан юнәлеш буенча укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясе турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
3. «Максатчан юнәлеш буенча укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен гражданнарны сайлап алу тәртибе турында» 2015 елның 15 апрелендәге 196 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма
комитеты карарына
1 нче кушымта

**Югары белем бирү мәгариф оешмаларында максатчан юнәлеш буенча укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составы**

Комиссия рәисе:

Гайнетдинов И. Ф. – Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары.

Комиссия рәисе урынбасары:

Мөхәрләмов Р. К. - "Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе" МКУ начальнигы

Комиссия секретаре:

Ахмадеева Э. Д. - "Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе" МКУнең баш белгече

Комиссия әгъзалары:

1. Сәгъдиев И. Н. - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы
2. Заһидуллин Р. Р. - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы
3. Петров И.И. - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы
4. Дәүлиев Г. Д. - "Балтач район үзәк хастаханәсе" ДАССУнең баш табибы (килешү буенча);
5. Гыйльметдинова Л. Н. - Балтач муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең кадрлар буенча консультанты (килешү буенча);

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма
комитеты карарына
2 нче кушымта

**Югары белем бирү мәгариф оешмаларында максатчан юнәлеш буенча укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясе турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Югары белем бирү мәгариф оешмаларында максатчан юнәлеш буенча укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясе эшчәнлеге (алга текст буенча - комиссия) "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль Закон, "Урта һөнәри һәм югары белем бирү мәгариф программалары буенча максатчан укыту турында" 2020 елның 13 октябрендәге 1681 номерлы РФ Хөкүмәте карары, "Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү мәгариф оешмаларына максатчан кабул итүне оештыру һәм уздыру тәртибе буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында" 2014 елның 19 ноябрендәге 886 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.2. Комиссия эше Балтач муниципаль районының төрле юнәлештәге (профильдәге) югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә булган ихтыяҗын исәпкә алып башкарыла.

2. Комиссиянең бурычлары һәм функцияләре

2.1. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- процедураларның гаделлек (объективлык) һәм ачыклык факторларын үтәп, максатчан кабул итү квоталары кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмаларында укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен иң әзерлекле һәм сәләтле абитуриентларны сайлап алу;

- Балтач муниципаль районына максатчан юнәлешләр бүлеп бирү буенча Татарстан Республикасы югары уку йортлары белән хезмәттәшлек итү.

2.2. Комиссиянең төп функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

- максатчан юнәлеш буенча югары уку йортларында укырга дәгъвачылар чыгарылыш сыйныф укучылары кандидатураларын карау эшен оештыру;

- максатчан кабул итү кысаларында укуга җибәрелә торган кандидатларның ахыргы исемлеген төзү һәм раслау.

3. Комиссия эшен оештыру

3.1. Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны максатчан җыюны оештыру буенча координатор булып "Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе" МКУ (алга таба - Идарә) тора.

3.2. Идарә:

- максатчан юнәлеш буенча югары уку йортларында укырга дәгъвачылар гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар исемлеген төзи;

- чыгарылыш сыйныф укучыларыннан кирәкле документларны кабул итә, аларны дөрес рәсмиләштерүгә, тулысынча тутыруга, шулай ук документларның дөреслегенә тикшерә;

- максатчан юнәлеш буенча югары уку йортларында укырга дәгъвачылар чыгарылыш сыйныф укучылары исемлеген, кирәкле материаллар белән бергә конкурс комиссиясенә карап тикшерүгә тапшыра.

3.3. Конкурс комиссиясе тәкъдим ителгән материаллар нигезендә чыгарылыш сыйныф укучыларын конкурс нигезендә сайлап алу үткәрә һәм югары уку йортларына максатчан кабул итү өчен тәкъдим итә.

Конкурс комиссиясе составы Балтач район башкарма комитетының муниципаль акты белән раслана.

Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдән һәм 5 комиссия әгъзасыннан тора.

Комиссия әгъзаларын алыштыру, башка затлар тарафыннан вазыйфаларны үтәү очракларыннан тыш, мөмкин түгел.

Конкурс комиссиясе рәисе комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

Конкурс комиссиясе секретаре комиссия утырышларына материаллар әзерләүне тәэмин итә, комиссия әгъзаларына утырыш чакырылу турында хәбәр итә, көн тәртибе турында комиссия әгъзаларына мәгълүмат бирә, утырыш беркетмәләрен алып бара, конкурс комиссиясе рәисе кушуы буенча башка функцияләрне башкара. Комиссия секретаре итеп Мәгариф идарәсеннән комиссия әгъзасы билгеләнә.

Комиссия үз эшен утырышлар формасында башкара. Комиссия утырышларын үткәрү тәртибен аның рәисе билгели. Әгәр утырышта аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

Утырышта конкурс сайлап алуын үткәргәндә комиссия түбәндәгеләрне башкара:

- студентның планлаштырылган чыгарылыш елына дәгъвачылар исемлеген районның кадрларга булган ихтыяҗына туры килү-килмәүгә тикшерә;

- юнәлеш биргән гомуми белем бирү учреждениесендә укучылар саны үзгәрү перспективаларын анализлый;

- эш бирүче булып торучы оешмага карата үзгәртеп кору, кушу перспективаларын ачыклый;

- чыгарылыш сыйныф укучысының агымдагы өлгерешен анализлый.